# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге Мөслим торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

29.11. 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2021 елның 22 ноябрендә 08 сәгать 30 минутта, 09 сәгать 00 минутта, 09 сәгать 30 минутта, 10 сәгать 00 минутта, 10 сәгать 30 минутта, 11 сәгать 00 минутта, 13 сәгать 00 минутта, 14 сәгать 00 минутта, 14 сәгать 30 минутта, 15 сәгать 00 минутта, 15 сәгать 20 минутта, 15 сәгать 30 минутта, 16 сәгать 00 минутта, 16 сәгать 30 минутта, 23 ноябрендә 08 сәгать 00 минутта, 08 сәгать 30 минутта, 13 сәгать 00 минутта, 15 сәгать 00 минутта, 16 сәгать 00 минутта, 24 ноябрендә 08 сәгать 00 минутта, 09 сәгать 30 минутта, 11 сәгать 30 минутта, 13 сәгать 00 минутта, 27 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 10 сәгать 00 минутта, 11 сәгать 00 минутта, 14 сәгать 00 минутта, 15 сәгать 00 минутта этаплап узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2022 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Мөслим торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм ветераннарына, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстандагы һәм Чечен Республикасында хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә инвалидларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итәргә;
- Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудырырга;
- Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудырырга, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештырырга;
- Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештырырга,
- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештырырга;
- Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирергә;
- Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашырга;
- Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тотарга;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, юынтык суны чыгаруны оештырырга;
- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә;
- Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештырырга».

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 6634 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 3781, бу 57% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 3711 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 70 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим униципаль районы Мөслим авыл җирлегенең Мөслим торак пунктында гражданнар җыены узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Мөслим торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм ветераннарына, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстандагы һәм Чечен Республикасында хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә инвалидларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүгә;
- Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыруга;
- Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыруга, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыруга;
- Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыруга;
- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыруга;
- Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирүгә;
- Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруга;
- Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тотуга;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, юынтык суны чыгаруны оештыруга;
- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә;
- Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыруга.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Мөслим авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы М.А.Байрханов